# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Кадер авыл җирлегенең Федот торак пунктында
2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**12.11.2025 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кадер авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Федот торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Кадер авыл җирлеге Федот торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге бүлектә укучы студентлардан, I группа инвалидлар, ялгыз өлкәннәрдән һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның гаиләләреннән кала.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (торак пункт эчендәге Үзәк урамында юлны ремонтлау).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегенең Федот торак пункты территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырырга, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) кабул ителгән көннән 7 көн дәвамында (Кадер авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) урнаштырырга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Кадер авыл җирлеге башлыгы** **Л.Н. Барсукова**